| | |
|---|---|
| **СОВЕТ МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 нче июль Мөрәле авылы №37

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл жирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге бюджеты төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 20021 елның 29 ноябрендәге 84-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл жирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл жирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 31 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге бюджеты төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге бюджеты төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«6 статья. Бюджет процессы принциплары**

Җирлекнең бюджет процессы Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән Россия Федерациясе бюджет системасы принципларына нигезләнә:

- Россия Федерациясе бюджет системасының бердәмлеге;
- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәр, чыгымнар һәм бюджет кытлыкларын финанслау чыганакларын бүлү (-бюджетларның мөстәкыйльлеге;
- Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең бюджет хокукларының тигезлеге;
- керемнәр, чыгымнар һәм бюджет кытлыкларын финанслау чыганаклары

чагылышының тулылыгы;

- бюджетның балансслылыгы;
- бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелеге;
- бюджет чыгымнарының гомуми (җыелма) капламалары;
- үтә күренмәлелек (ачыклык);

гражданнарның бюджет процессында катнашу тәртибе;

- бюджетның дөреслеге;
- бюджет акчаларының адреслы һәм максатчан характерындагы;
- бюджет чыгымнарының ведомство буйсынуы;
- кассаның бер булуы.».

16 статьяда:

13 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган йөкләмәләр күләме;»;

19 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган йөкләмәләр күләме;»;

23 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында җирлек тарафыннан бирелгән чит ил валютасында муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган йөкләмәләр күләме.».

1.2. 20 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджетка акча җәлеп итү күләмнәре (чираттагы финанс елы) Россия Федерациясе бюджет кодексының 103 һәм 104 статьялары нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле финанс елына җирле бюджет турындагы карар белән расланган инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш, муниципаль эчке һәм тышкы бурыч алулар программалары белән билгеләнә, һәм һәм тиешле финанс елында акчаларны җәлеп итүнең гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлтелгән акчаларның гомуми суммасыннан һәм җирлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән артмаска тиеш.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://muralin-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Кайбыч муниципаль районы
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Зиннәтуллин